# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«05» август 2019 ел Иштирәк авылы №2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге халкының катнашу хокукларын саклау максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсе 4 өлешенә, Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

### КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында 2019 елның 6 августыннан да соңга калмыйча урнаштырырга .

3. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;
- халык тыңлауларын үтәкәрү вакытын: 2019 елның 5 сентябрендә 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – ТР, Тукай муниципаль районы, Иштирәк авыл җирлеге, Үзәк урамы, 116А йорты (Иштирәк авыл мәдәният йорты);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын – ТР, Тукай муниципаль районы, Иштирәк авылы, Үзәк урамы, 216А йорт, (эш көннәрендә-8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр);
- халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2019 елның 3 сентябренә кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С. Гарифуллина